**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ КАЗКЕЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423761, село Казкеево,
ул. Первомайская,дом 2а,
Тел. 3-44-46

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ КӘЗКӘЙ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423761, Кәзкәй авылы,
Беренче май., 2а нчы йорт.
Тел.3-44-46

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2023 №19

Актаныш муниципаль районының "Кәзкәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Актаныш муниципаль районының "Кәзкәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында.

Прокурорның 2023 елның 30 июнендәге 02-08-02-2023 номерлы протестын үтәү йөзеннән "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 01.04.2022 N 90-ФЗ "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Кәзкәй авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. 2015 елның 10 гыйнварындагы N 3 номерлы карары (кертелгән үзгәрешләр белән: 2015 елның 25.декабрендәге № 15, 2018 елның 05 июлендәге №14) белән расланган "Актаныш муниципаль районының «Кәзкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Актаныш муниципаль районының «Кәзкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 16нчы пунктның икенче абзацында «яисә тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләр бирү» сүзләрен «үзләренең чыгымнары турында белешмәләр бирү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган белешмәләр тапшыру йә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләренә алмаштырырга, «йә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында ялган яисә дөрес булмаган белешмәләр тапшырмау яисә алдан ук тапшырмау» сүзләрен «яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләрне тапшырмау,

федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, түлы булмаган белешмәләр тапшырырга, йә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында күрәләтә белешмәләр тапшырырга;

1.2. Нигезләмәнең 6 пунктындагы «в» пунктчасында һәм 13 пунктындагы «акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "Кәзкәй авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рәислек итүче Н.К.Хәҗҗәтов